СОВЕТ КЕМЕШ-КУЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.61, с. Кемеш-Куль, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422147

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӨМЕШ-КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 61 нче йорт, Көмеш-Күл авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422147

тел.(факс): (85563) 2-46-38; e-mail: KemKul.Mam@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар
17 сентябрь 2018 ел | №2-32

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге №1-28 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131 -ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге №1-28 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 6 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

бункер - зур габаритлы калдыкларны җыю өчен билгеләнгән чүп-чар җыю өчен савыт;

1.2. 6 пунктның 11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

контейнер - эре габаритлы калдыклардан тыш каты коммуналь калдыкларны туплау өчен билгеләнгән чүп-чар җыю өчен савыт чүп-чар савыты;

1.3. 6 пунктның 12 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

контейнер мәйданчыгы - каты коммуналь калдыклар җыелу урыны, әйләнәтирә мохитне саклау өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары һәм халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзекләндерелгән һәм контейнерлар һәм бункерлар урнаштыру өчен билгеләнгән урын;

1.4. 9 пунктның 28 пунктчасын төшереп калдырырга;

1.5. 127 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Капиталь төзелеш объектлары номерлары, күрсәтмә һәм йорт билгеләре белән җиһазландырылырга тиеш.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы торак пунктларының барлык урамнарында Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә (рус, татар) урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр (1 нче кушымта, 2 нче кушымта) билгеләнә.

1). Бина фасадларына түбәндәгеләрне урнаштыру тыела:

- урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләрне ирекле рәсмиләштерү һәм урнаштыру;
- башка күрсәткечләрне рәсмиләштерү һәм урнаштыру;
- расланган үрнәкләргә туры килми торган урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр урнаштыру;
- күрсәткечләр, урамнар исемнәре һәм йорт номерлары белән янәшә торучы элмә такталар, шулай ук аларны кабул итүне кыенлаштыра торган объектларны урнаштыру;
- чыгып торучы фасад элементлары янында яки фасадның эчкә кереп торучы участокларында, декор элементларында, карнизларда, капкаларда урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләрне урнаштыру;
- урам исемнәре һәм йорт номерлары белән билгеләнгән урыннан күрсәткечләрне күчерү.

2). Биналар урам исемнәре һәм йорт номерлары күрсәтелгән күрсәткечләр белән җиһазландырылырга тиеш, алар чиста һәм төзек хәлдә булырга тиеш.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы авыл җирлегенең барлык торак пунктларында ике вариантта урнаштырыла торган урам исеме һәм йорт номеры күрсәтелгән күрсәткечнең күләме һәм формасы № 3-4 кушымталарда күрсәтелгән:

1 нче Вариант :

- күрсәткечнең төсе: шрифт – ак төстә, фон – зәңгәр төстә;
- шрифт: «Arial»;
- номер билгесе белән берләштерелгән аншлагның габарит зурлыгы: урам исеме озынлыгы буенча х 350 мм;
- номер билгесенең габарит зурлыгы: 350 х350 мм.

2 нче Вариант :

- күрсәткечнең төсе: рус телендә исеме: шрифт – зәңгәр төстә, фон - ак төстә; татар телендә исеме: шрифт – ак төстә, фон – зәңгәр төстә;

- шрифт: «Arial»;
- номер билгесе белән берләштерелгән аншлагның габарит зурлыгы: урам исеме озынлыгы буенча х 350 мм;;
- исеме озынлыгы буенча х 350 мм;.

4). Урам исемнәре һәм йорт номерлары күрсәтелгән күрсәткечләр биналарның фасадларына түбәндәге таләпләр нигезендә урнаштырыла:
- урам исемнәре һәм йорт номерлары күрсәтелгән күрсәткечләр җәяүлеләр һәм транспорт хәрәкәте шартларын, биналарның архитектурасын, яктыртылышын, яшел утыртмаларны исәпкә алып, яхшы күренә торган урыннарда урнаштырыла;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы И.Н.Сәләхетдиновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.Н.Сәләхетдинов.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге
Советының 2018 елның 11 апрелендәге №1-28
карары белән расланган «Татарстан
Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Көмеш-Күл авыл
җирлеге» муниципаль берәмлеге
территориясен төзекләндерү
кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү турындагы
карарына 1 нче кушымта

**Номер билгесе белән Аншлаг**

1 Вариант

| МАТЕРИАЛ | ТӨС |
|---|---|
| штамповка. 0,8 мм калынлыктагы тигез калайдан, буяу техникасы-полимер | Фон - зәңгәр, Билге- ак |



2 Вариант

| МАТЕРИАЛ | ТӨС |
|---|---|
| штамповка. 0,8 мм калынлыктагы тигез калайдан, буяу техникасы-полимер | Рус телендә исеме: шрифт - зәңгәр, ак знаклар; татар телендщге исеме: шрифт – ак төстә, зәңгәр знаклар; |



Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге №1-28 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карарына 2 нче кушымта

**Номерлы знак**

| МАТЕРИАЛ | ТӨС |
|---|---|
| штамповка 0,8 мм калынлыктагы тигез калайдан, буяу техникасы-полимер | Фон - зәңгәр, ак знак |

